Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 18 ноябре №2

2024 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлеге Түбән Чыршылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлеге Түбән Чыршылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, срокльы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш ш, һәр балигъ булган кешедән 500 (Биш йөз) сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы итеп оештыру:

- Түбән Чыршылы: Калмык урамы, Мельничная урамы, Мокрый Куст урамы, Озерная урамы, Плетеная урамы, Совет урамы, Тукай урамы, Үзәк урамы буенча авылда урам яктыртуга техник хезмәт күрсәтү.

2)торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Түбән Чыршылы авылында Совет, Озерная урамнары буенча вак таш юлларны чокырлы ремонтлау.

- Түбән Чыршылы торак пунктында Калмык урамы, Мельничная урамы, Мокрый Куст урамы, Озерная урамы, Плетеная урамы, Совет урамы, Тукай урамы буенча юлларны кардан чистарту.

3) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын тоту:

- Түбән Чыршылы авылының үзәк 89а урамындагы традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар төзү

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Түбән Чыршылы авылы административ бинасында-Үзәк урам, 105 йорт, балалар бакчасы бинасында -Совет урамы, 8 йорт, Үзәк урам, 23 йорт буенча, «АФ-Спартак» ҖЧҖ идарәсе бинасында-Совет урамы, 2 йорт , Мордва Ивановка авылында-авыл клубы бинасында-Горная урамы, 27 йорт, Мордва Ивановка авылында Совет урамы 13 йорт буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск

бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Н.Я. Хәйруллина